**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6260**
**19.10.2018**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ санлы Законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җирдән файдалануны контрольдә тоту бүлеге эшчәнлегенең административ регламентын раслау турында» 2009 елның 15 маендагы 1980 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җирдән файдалануны контрольдә тоту бүлеге эшчәнлегенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 4 декабрендәге 5654 нче карары;

3) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җирдән файдалануны контрольдә тоту бүлеге эшчәнлегенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 26 мартындагы 1914 нче карары;

4) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җирдән файдалануны контрольдә тоту бүлеге эшчәнлегенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 17 маендагы 3157 нче карары;

5) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җирдән файдалануны контрольдә тоту бүлеге эшчәнлегенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 6 июлендәге 4429 нчы карары;

6) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җирдән файдалануны контрольдә тоту бүлеге эшчәнлегенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 28 ноябрендәге 8658 нче карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны тиешле мәгълүмат системаларында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында (www.nabchelny.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы А.Ә. Насыйбуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 19 октябрендәге
6260 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча
муниципаль функцияне үтәүнең
административ регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ регламент (алга таба – Регламент) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен (алга таба – муниципаль җир контроле) гамәлгә ашырганда административ процедураларның (административ гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Муниципаль җир контроле Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының функциясе булып тора.

1.2. Муниципаль җир контроле вәкаләтле органы булып «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – муниципаль җир контроле органы) торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектларына карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыралар.

Вазыйфаи затлар муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда дәүләт җир күзәтчелеге органнары, суд органнары, хокук саклау органнары, прокуратура органнары, экспертлар һәм эксперт оешмалар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар белән үзара эшчәнлек алып баралар.

1.3. Муниципаль җир контроле түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе («РФ законнар җыентыгы», 04.08.2014, №31, ст. 4398);

-Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) («РФ законнар җыентыгы», 29.10.2001, №44, ст. 4147);

- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) («РФ законнар җыентыгы», 07.01.2002, №1 (1 бүлек), ст. 1);

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми

принциплары турында» 2003 елның 131-ФЗ санлы Федераль закон («РФ законнар җыентыгы», 06.10.2003, №40, ст. 3822);

- «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль закон («РФ законнар җыентыгы», 08.05.2006, №19, ст. 2060);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон) (алга таба – 294-ФЗ санлы Федераль закон) («РФ законнар җыентыгы», 29.12.2008, №52 (1 бүлек), ст. 6249);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 нчы Карары) («РФ законнар җыентыгы», 12.07.2010, №28, ст. 3706);

- Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы («Российская газета», №85, 14.05.2009);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт җир күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарының муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органнар белән үзарә эшчәнлеге кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге 1515 нче карары («РФ законнар җыентыгы», 05.01.2015, №1 (II бүлек), ст. 298);

- Татарстан Республикасы Җир кодексы («Республика Татарстан», №10-11, 22.01.2005);

- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ санлы Законы (алга таба – Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы) («Республика Татарстан», №148, 16.10.2015);

- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Законы («Республика Татарстан», №155-156, 03.08.2004);

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның8 декабрендәге 6/5 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы («Челнинские известия», №235-237, 10.12.2005, «Челнинские известия», №249-250, 30.12.2005)

- Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/15 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында нигезнамә («Челнинские

известия», № 86, 15.11.2013);

- әлеге Регламент.

1.4. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләрнең предметы булып дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан җир мөнәсәбәтләре объектларына карата, бозган өчен Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ яки башка җаваплылык күздә тотылган Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәү тора.

Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата муниципаль җир контроле, Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, 294-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына карата муниципаль җир контроле юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Гражданнарга карата муниципаль җир контроле Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

294-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсенең 5 пункты нигезендә күрсәтелгән контроль чаралар вазыйфаи затлар һәм кирәк очракта, 294-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә, тикшерүләр үткәрүгә җәлеп ителә торган юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның документларын һәм аларның эшчәнлеге турында башка мәгълүматны карап тикшерү, эшчәнлекне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән затлар тарафыннан файдаланыла торган производство объектларын карау һәм тикшерү буенча, планлы (рейд) тикшерүләр, аеруча саклана торган табигать территорияләрен, урман участокларын, җир участокларын тикшерү буенча, шулай ук мәҗбүри таләпләр һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылуның зыян килү фактлары белән сәбәп-тикшерү бәйләнешен билгеләүгә юнәлдерелгән экспертиза һәм тикшеренүләр үткәрү буенча экспертлар, эксперт оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.5. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда муниципаль җир контроле вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары.

1.5.1. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аларга йөкләнгән бурычларны үтәгәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

- планлы, планнан тыш, документар (камераль), күчмә тикшерүләр үткәрергә;

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән бәйләнешсез контроль чаралар үткәргәндә җир мөнәсәбәтләре объектларын административ тикшерүне үткәрергә;

- әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендә җир законнарын үтәү

мәсьәләләре буенча үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирергә;

- хезмәт таныклыгын күрсәтеп, оешмаларга һәм объектларга керергә, милектә, файдалануда, арендада һәм үз карамагында булган җир участокларын тикшерергә;

- тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар (җир законнары үтәлешен тикшерү актлары, территорияне тикшерү актлары, җир участогының мәйданын үлчәү актлары, җир участоклары буенча белешмәләр), фототаблицалар, алар белән милекчеләрне, хуҗаларны, файдаланучыларны, җир участокларын арендалаучыларны мәҗбүри таныштыру турында тиешле белдерү кәгазьләре төзергә;

- закон эшчәнлеген гамәлгә ашыруга комачаулаучы гамәлләрне булдырмауда яисә бетерүдә, шулай ук җир законнарын бозуда гаепле затларны билгеләүдә булышлык күрсәтү өчен эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

- территориаль органнардан, федераль башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, вазыйфаи затлардан, гражданнар, милекчеләрдән, хуҗалардан, файдаланучылардан, җир участоклары арендаторларыннан муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җирләрнең торышы һәм алардан файдалану турында белешмәләрне һәм материалларны, шул исәптән җир участокларына һәм аларда булган объектларга хокукны таныклаучы документларны, җир участокларыннан файдаланучы затлар турында мәгълүматларны соратып һәм бушлай алырга;

- гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне карау өчен, тиешле дәүләт органнарына тапшыру закон нигезендә каралган һәм әлеге орган (вазыйфаи зат) тарафыннан аның законлы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле, җир законнарын бозу турында, шул исәптән вазыйфаи затның (органның) законлы боерыгына буйсынмау, (органның) вазыйфаи затның законлы эшчәнлегенә комачаулау, органга (вазыйфа затка) мәгълүматларны (мәгълүматны) тапшырмау яки үз вакытында тапшырмау яисә  муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органга (вазыйфаи затка) мондый мәгълүматларны (мәгълүматны) тулы булмаган күләмдә яисә хаталы рәвештә тапшыру буенча материаллар җибәрергә;

- җир мөнәсәбәтләре белән бәйле мөрәҗәгатьләр буенча күзәтчелек һәм контроль органнары белән уртак тикшерүләр үткәрергә;

- үз компетенциясе чикләрендә юридик, вазыйфаи затлар һәм гражданнар тарафыннан җир законнары таләпләре үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

- тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан мәҗбүри таләпләр яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта, муниципаль җир контроленең тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә  ачыкланган кимчелекләрне бетерүне, аларны кисәтү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүне

булдырмау, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү буенча чаралар, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә тиеш;

- тикшерү үткәргәндә юридик зат, аның филиалы, вәкиллеге, структур бүлекчәсе, шәхси эшмәкәр, граждан эшчәнлеге, аларның биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, җир участокларында шундый объектларны эксплуатацияләү турыдан-туры гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерү, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы тудырса яки мондый зыян килгән очракта, муниципаль җир контроле органы зыян китерүне булдырмый калу буенча кичекмәстән чаралар күрергә һәм гражданнар, шулай ук башка юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, контроль һәм күзәтчелек органнары игътибарына зыян килү куркынычы һәм аны булдырмый калу ысуллары турында теләсә нинди уңайлы ысул белән мәгълүмат җиткерергә тиеш.

1.5.2. Вазыйфаи затлар түбәндәгеләр буенча муниципаль җир контролен гамәлгә ашыралар:

- җирдән файдалану буенча таләпләрне үтәү;

- җир участокларын үз белдеге белән биләүне яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хокук билгеләүче документлардан башка файдалануны булдырмаучы тәртипне үтәү;

- җир участокларын максатчан билгеләнеш буенча файдалану;

- муниципаль милектәге җир участокларына, дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына һәм аларда урнашкан күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алу һәм төзелгән килешүләр булу;

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар тарафыннан җир участокларын үзләштерүнең гамәлдәге законнар белән билгеләнгән срокларын үтәү;

- җир участокларына хокукларны тапшыру тәртибен үтәү;

- җирләрне тиешенчә кире кайтару;

- муниципаль милектәге җир участокларына, дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына аренда түләве;

- межа һәм геодезия билгеләре булу һәм аларның сакланышы;

- муниципаль җир контроле органының законлы күрсәтмәсен вакытында үтәү;

- законда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итү;

- җирләрдән файдалану һәм аларны саклау мәсьәләләре буенча җир законнарының башка таләпләрен үтәү.

1.5.2.1. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, мәҗбүри таләпләрне,

муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында муниципаль җир контроле органы, ел саен алар тарафыннан раслана торган бозуларны профилактикалау программалары нигезендә, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.

Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында муниципаль җир контроле органы:

1) «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда, үтәлешен бәяләү муниципаль җир контроле предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең исемлеген, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстларын урнаштыруны тәэмин итә;

2) мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү буенча кулланмалар эшләү һәм бастырып чыгару, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре үткәрү юлы белән һәм башка ысуллар белән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра. Мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үзгәргән очракта, муниципаль җир контроле органы мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның гамәлгә керү сроклары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне гамәлгә кертүгә һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр әзерли һәм тарата;

3) тиешле эшчәнлек өлкәсендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру практикасын даими (кимендә елга бер тапкыр) гомумиләштерүне һәм «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда тиешле гомумиләштерүләрне урнаштыруны, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның аеруча еш очрый торган очракларын күрсәтеп, мондый бозуларны булдырмау максатларында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата рекомендацияләр белән тәэмин итә;

4) әгәр дә башка тәртип федераль закон белән билгеләнмәгән булса, 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.2 маддәсенең 5-7 бүлекләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтә.

Федераль законда башкача билгеләнмәгән очракта, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә,

әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына керүче аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерү яисә күрсәтелгән нәтиҗәләргә куркыныч тудыру турында расланган мәгълүматлар булмаган очракларда, муниципаль җир контроле органында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән үзара бәйләнешсез гамәлгә ашырылган контроль чараларын тормышка ашыру барышында алынган яисә җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматта, мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш) әзерләнүче хокук бозулар турында яки хокук бозу билгеләре турында мәгълүматлар булганда, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы юридик затка, шәхси эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтәләр һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу турыда мондый кисәтүдә билгеләнгән срокта муниципаль җир контроле органына хәбәр итәргә тәкъдим итәләр.

Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүдә тиешле мәҗбүри таләпләргә, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә, аларны күздә тоткан норматив хокукый акт, шулай ук юридик затның, шәхси эшкуарның, гражданның конкрет нинди эшләре (эш итмәүләре) бу таләпләрне бозуга китерә алуы яисә китерүе турында мәгълүмат булырга тиеш. Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турындагы мәгълүматлардан тыш, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәгълүмат һәм документлар бирү таләпләрен үз эченә ала алмый.

Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан мондый кисәтү һәм аларны карап тикшерүгә каршы җавап бирү тәртибе, мондый кисәтү үтәлеше турында хәбәр итү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән.

1.5.2.2. 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.3 маддәсе нигезендә муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары үз компетенцияләре чикләрендә, муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган мондый чараларны үткәрү буенча йөкләмәләр нигезендә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән

бәйләнешсез контроль чаралары үткәрәләр.

Муниципаль җир контроле органының юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән үзара бәйләнеше таләп ителми торган контроль чараларына түбәндәгеләр керә:

1) 294-ФЗ санлы Федераль законның 13.2 маддәсе нигезендә территорияләрне, акваторияләрне планлы (рейд) карап чыгу (тикшерү);

2) җир мөнәсәбәтләре объектларын административ тикшерү;

3) реклама таратканда мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү;

4) «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырганда мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү;

5) юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм граждан тарафыннан (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль җир контроле органына бирелә яки юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм гражданнарга федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралмаган бурычларны йөкләмичә (шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында) муниципаль җир контроле органы тарафыннан алынырга мөмкин булган шундый затларның эшчәнлеге яисә гамәлләре турындагы мәгълүматны анализлау юлы белән мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен күзәтү;

6) контроль чараларның федераль законнарда билгеләнгән башка төрләре һәм формалары.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чаралары муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган мондый чараларны үткәрүгә йөкләмәләр нигезендә, үз компетенциясе чикләрендә муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелә.

294-ФЗ санлы Федераль законның 8.3 маддәсендәге 2 бүлегендә күрсәтелгән биналарны рәсмиләштерү һәм карап тоту тәртибе һәм муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары тарафыннан юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән үзара бәйләнешсез контроль чаралары нәтиҗәләрен, шул исәптән планлы (рейд) тикшерүләрнең, тикшеренүләрнең, үлчәү, күзәтүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) тиешле өлкәләрендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

294-ФЗ санлы Федераль законның 8.3 маддәсендәге 1 бүлегендә күрсәтелгән контроль чараларын үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларга чик кую буенча

чаралар күрәләр, шулай ук 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсендәге 2 бүлекнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча, муниципаль җир контроле органы җитәкчесенә, кирәк булганда, юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү өчен ачыкланган бозулар турында мәгълүматны үз эченә алган дәлилләнгән язма гариза җибәрәләр.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чараларын үткәрү барышында әзерләнүче хокук бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозу билгеләре турында 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.2 маддәсендәге 5-7 бүлекләрендә күрсәтелгән мәгълүматлар алынган очракта, муниципаль җир контроле органы юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү җибәрә.

1.5.2.3. Муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затларының бурычлары:

- мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәү;

- Россия Федерациясе законнарын, тикшерелә торган юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

- тикшерүне, муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең аны үткәрү турында боерыгы (приказы) нигезендә, аның билгеләнешенә туры китереп үткәрү;

- тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта гына, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыгын, муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең боерыгы (приказы) күчермәсен күрсәтеп, 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсе 5 бүлегендә каралган очракта, тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килешенү турында документ күчермәсен күрсәтеп кенә үткәрү;

- тикшерү үткәргәндә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, гражданнарга яки аларның вәкиленә катнашырга комачаулык итмәү һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү;

- тикшерү үткәргәндә катнашкан җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, гражданнарга яки аларның вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүматларны һәм документларны бирү;

- җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, гражданнарны яки аларның вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

- җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, физик затны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати эшчәнлек кысаларында

алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән таныштыру;

- ачыкланган хокук бозу фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, күрсәтелгән чараларның хокук бозуларның авырлык дәрәҗәсенә туры килүен, аларның кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян килүнең, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның потенциал куркынычын исәпкә алу, шулай ук гражданнарның, шул исәптән юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймау;

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан шикаять бирелгәндә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз эшләренең нигезлелеген исбатлау;

- тикшерү үткәрүнең 294-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән срокларын үтәү;

- юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, гражданнардан Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм башка мәгълүматларны бирүне таләп итмәү;

- күчмә тикшерү башланыр алдыннан җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, гражданнар яки аларның вәкиленең үтенече буенча, тикшерү үткәргәндә нигезләнә торган әлеге Регламент нигезләмәләре белән таныштыру;

- журнал булган очракта, тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән тикшерү турында язып кую (тикшерүләрне исәпкә алу журналының типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче приказы белән расланган).

1.5.3. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуксыз:

- мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тикшерү, әгәр андый таләпләр муниципаль җир контроле органы исеменнән эш итүче әлеге вазыйфаи затларның вәкаләтләренә кермәсә;

- СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәүне, шулай ук Россия Федерациясе законнарында мәҗбүри куллану каралмаган норматив документларның таләпләрен үтәүне тикшерү;

- мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә бастырып чыгарылмаган таләпләрне үтәүне тикшерү;

- планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыру, әгәр җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, граждан яки аның вәкиле тикшерүдә катнашмаган очракта, андый тикшерү 294-ФЗ санлы Федераль

законның 10 маддәсе 2 бүлеге 2 пунктының «б» пунктчасында каралган нигездә үткәрелгән очрактан тыш, шулай ук җир участоклары милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир хуҗаларына һәм җир участоклары арендаторларына тиешенчә хәбәр җиткерелгән очракта, җир законнары таләпләрен үтәүне тикшерү;

- тикшерү объектлары булып саналмаган яки тикшерү предметына карамаган документларны, мәгълүматны, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм производство объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны таләп итү, шулай ук андый документларның төп нөсхәләрен кулланудан алу;

- муниципаль җир контроле органына тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль таныклауны таләп итү;

- илкүләм стандартлар, үрнәкләр, пробалар сайлап алу кагыйдәләре һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәү методлары, техник регламентлар яки аларның үз көченә керү көненә кадәрге башка норматив техник документлар һәм тикшерү, сынау, үлчәү методлары һәм кагыйдәләре белән билгеләнгән нормалардан артып киткән һәм билгеләнгән форма буенча күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу турында беркетмәләр рәсмиләштермичә, аларны тикшерү, сынау, үлчәүне үткәрү өчен әйләнә-тирә мохит объектларын һәм производство объектларын тикшерү пробаларын, продукция үрнәкләрен алу;

- тикшерү үткәрү нәтиҗәләрендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт буенча һәм башка закон белән саклана торган сер булган (Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш) мәгълүматны тарату;

- тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттыру;

- юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга контроль чараларны алар хисабына үткәрү турында күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашыру;

- юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, гражданнардан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан аерым исемлеккә кертелгән оешмалар карамагындагы рөхсәт бирү документларын да кертеп, документлар һәм (яки) мәгълүматлар таләп итү;

- күчмә тикшерү үткәргәндә, юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, гражданнан документар тикшерү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүмат тапшыруны таләп итү, юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, гражданнан тикшерү үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итү.

Муниципаль җир контроле органы тикшерү үткәрү турында боерык яки приказ кабул ителгәннән соң ведомствоара мәгълүмати эшчәнлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

1.6. Муниципаль җир контроле буенча чараларны гамәлгә ашыруга

мөнәсәбәтле затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.6.1. Тикшерү үткәргәндә җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, граждан, аның вәкаләтле вәкиле түбәндәгеләргә хокуклы:

- тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашу, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү бирү;

- муниципаль җир контроле органыннан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына караган һәм әлеге Федераль закон нигезендә тапшырылырга тиешле мәгълүматны алу;

- муниципаль җир контроле органыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кергән яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагындагы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышу;

- ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яки) мәгълүматларны муниципаль контроль органына үз инициативасы белән бирү;

- тикшерү нәтиҗәләре белән танышу һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының аерым эш итүләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтү;

- муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирү;

- Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яисә Россия Федерациясе субъектындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итү.

1.6.2. Тикшерүләр үткәргәндә юридик затлар җитәкчеләрнең, башка вазыйфаи затларның яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләренең катнашуларын тәэмин итәргә бурычлы; шәхси эшмәкәрләр, гражданнар катнашырга яки мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә бурычлы.

1.6.3. Муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәрүгә комачаулык итүче затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

1.7. Муниципаль функцияне үтәү нәтиҗәләрен тасвирлау.

Тикшерү үткәрә торган муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары тарафыннан планлы, планнан тыш тикшерүләр үткәрү нәтиҗәләре буенча түбәндәге документлар төзелә:

- юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның әлеге Регламентның 2 нче, 3 нче кушымталарында каралган форма буенча 2 нөсхәдә тутырылган, анда җир законнары таләпләрен бозу ачыкланган билгеләр булу яисә андый кимчелекләрнең булмавын күрсәткән (тикшерү

актының типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче приказы белән билгеләнгән) җир законнарын үтәүне тикшерү акты. Җир законнары таләпләрен бозу ачыкланган очракта, аның өчен Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ яки башка җаваплылык каралган, тикшерү (тикшереп чыгу) акты, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә чара күрү өчен, дәүләт җир күзәтчелеге органына һәм башка күзәтчелек һәм контроль органнарына җибәрелә;

- журнал булган очракта, тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән күчмә тикшерү турында язып кую (тикшерүләрне исәпкә алу журналының типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче приказы белән расланган).

Муниципаль җир контроле органына гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар керү муниципаль функцияне үтәү өчен нигез булып торган очракта, муниципаль функцияне үтәү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчегә җавап «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

## 2 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәү тәртибенә таләпләр

2.1. Муниципаль функцияне үтәү турында мәгълүмат бирү тәртибе.

2.1.1. Әлеге Регламент «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр чаллы шәһәренең рәсми сайтында (www.nabchelny.ru) урнаштырыла.

2.1.2. Муниципаль җир контроле органының урнашу урыны: 423805, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23.

Муниципаль җир контроле органының элемтә телефоны: (8552) 305711, 305910.

Мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен электрон адрес: okz255@mail.ru.

Муниципаль функцияне гамәлгә ашыручы муниципаль җир контроле органының структур бүлекчәләренең урнашу урыны турында мәгълүмат 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица

Муниципаль җир контроле функциясен гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр турында мәгълүматлар

| Муниципаль җир контроле органы | Адрес | Хезмәт күрсәтелә торган территория | Телефон |
|---|---|---|---|
| Җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлеге | Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23, 255, 256 кабинетлар | Яр Чаллы шәһәре | (8552)305711<br>(8552)305910 |

2.1.3. Муниципаль функцияне үтәү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне муниципаль җир контроле органына җибәрү өчен почта адресы: 423805, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23.

2.1.4. Муниципаль җир контроле органы структур бүлекчәләренең эш графигы:

- дүшәмбе-җомга – 8.00 дән 17.00 кадәр;
- шимбә, якшәмбе – ял көннәре;
- төшке аш вакыты – 12.00 дән 13.00 кадәр.

2.1.5. Муниципаль функцияне үтәү урыны:

- документар тикшерү вакытында – муниципаль җир контроле органының урнашу урыны буенча;
- күчмә тикшерү үткәргәндә – юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашу урыны буенча яки шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның яшәү урыны һәм аларның факттагы эшчәнлек алып бару урыны буенча.

2.1.6. Муниципаль функцияләрне үтәү тәртибе турындагы мәгълүмат муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан түбәндәгечә бирелә:

- турыдан-туры шәхси кабул итү кысаларында;
- язма рәвештә (почта аша мөрәҗәгать иткәндә әлеге Регламентның 2.1.3 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча);
- мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы аша.

Муниципаль функцияләрне үтәү тәртибе турындагы мәгълүмат муниципаль җир контроле органының рәсми сайтында урнаштырыла һәм яңартыла (әлеге Административ регламентка үзгәрешләр кертүгә карап).

2.2. Муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәрү өчен юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм гражданнардан түләү алуга юл куелмый.

Муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәрү өчен, шул исәптән тикшерүләр үткәрүгә җәлеп ителгән очракта, экспертлар һәм эксперт оешмаларның хезмәтләре өчен юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм гражданнардан түләү алынмый.

2.3. Муниципаль функцияләрне үтәү срогы.

Документар тикшерү (планлы һәм планнан тыш), күчмә тикшерү үткәрү (планлы һәм планнан тыш) срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына – 50 сәгатьтән, микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артырга тиеш түгел.

Тикшерү үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу кирәк булган очракта, тикшерү үткәрү муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка туктатып торылырга мөмкин, ләкин ун эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел. Тикшерү үткәрүне кабаттан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда территориядә, биналарда, төзелешләрдә, корылмаларда, бүлмәләрдә, башка кече эшмәкәрлек субъекты объектларында муниципаль җир контроле органының әлеге тикшерүгә бәйле эшләре туктатылып тора.

Планлы күчмә тикшерү үткәрә торган муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының дәлилле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү кирәклеге белән бәйле аерым очракларда, планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы шундый орган җитәкчесе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин ул 20 эш көненнән дә артык була алмый, кече предприятиеләргә карата – 50 сәгатьтән, микропредприятиеләр өчен 15 сәгатьтән дә артык түгел.

Үз эшчәнлекләрен Россия Федерациясенең берничә субъекты территорияләрендә гамәлгә ашыра торган юридик затларга карата 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләрендә каралган һәр тикшерүне үткәрү срогы юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрү срогы алтмыш эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел.

2.4. Муниципаль җир контроле буенча чаралар планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы нигезендә үткәрелә торган планлы тикшерүләр формасында, шулай ук законнар нигезендә оешмаларның һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәп планнан тыш тикшерүләр формасында гамәлгә ашырыла.

2.5. Тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр.

2.5.1. Планлы тикшерүләр муниципаль җир контроле органы тарафыннан эшләнгән еллык планнар нигезендә үткәрелә.

Планлы тикшерүнең предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан эшчәнлек алып бару процессында мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен тикшерү тора.

Муниципаль җир контроле органы планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 июненә кадәр срокта, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – План) проектын килешенү өчен – дәүләт җир контроле органына; планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның

1 сентябренә кадәр срокта, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль җир контроле урнашкан урын буенча прокуратура органына җибәрә.

Планлы тикшерүне Планга кертү өчен түбәндәгеләрдән соң өч ел үткән булу нигез булып тора:

1) юридик зат, шәхси эшмәкәр дәүләт теркәвенә алынганнан, гражданның җир мөнәсәбәтләре объектына (алга таба – җир участогы) хокуклары барлыкка килгәннән соң;

2) юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны соңгы планлы тикшерү үткәрү тәмамланганнан соң;

3) күрсәтелгән белдерү кәгазен бирүне таләп итә торган эшләр башкарылган яки хезмәтләр күрсәтелгән очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле өлкәсендә вәкаләтләнгән федераль башкарма хакимият органына бирелгән эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерү кәгазе нигезендә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаганнан соң.

294-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Планда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) планлы тикшерү үткәрелергә тиешле юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) исемнәре, шәхси эшмәкәрләр, гражданнарның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан урыннары яки шәхси эшмәкәрләрнең яшәү урыны һәм факттагы эшчәнлек алып бару урыны, гражданның яшәү урыны;

2) һәр планлы тикшерү үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерү үткәрүнең башлану датасы һәм сроклары;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыра торган муниципаль җир контроле органының исеме;

5) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль җир контроле органы тарафыннан планлы тикшерүне бергә үткәргәндә, андый тикшерүдә катнашучы барлык органнарның да исемнәре күрсәтелә.

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тикшерүне үткәрү турындагы боерык (приказ) әлеге Регламентка 1 нче кушымтада нигезендә рәсмиләштерелә (типовой форма Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче приказы белән расланган).

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан раслана.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы кызыксынган затларга аны Башкарма комитетның рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштыру юлы белән яки башка уңайлы ысул аша җиткерелә.

Планлы тикшерү үткәрү турында юридик затка яки шәхси эшмәкәргә, гражданга тикшерү башланганчы өч эш көненнән дә соңга калмый, муниципаль җир контроле органы тарафыннан, планлы тикшерү башлану

турында муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең боерыгы (приказы) күчермәсен, почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат һәм башка төрле уңайлы ысул белән җибәреп хәбәр ителә.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү өчен чикләүләр:

- планлы тикшерү юридик затны яки шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алганнан соң, гражданның җир участогына хокукы барлыкка килгәннән соң кимендә өч ел узгач үткәрелергә мөмкин;

- бер үк юридик затка яки шәхси эшмәкәргә, гражданга карата планлы тикшерү өч елга бер тапкырдан артмаган санда үткәрелергә мөмкин (сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәләрендә, социаль өлкәдә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән тыш).

Планлы тикшерү, 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә, документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

Муниципаль җир контролен оештыру һәм үткәрү тәртибендә муниципаль җир контроле органының вазыйфаи заты тарафыннан планлы тикшерү үткәргәндә, 6 нчы кушымтада каралганча тикшерү кәгазьләреннән (контроль сораулар исемлегеннән) файдалану бурычлары күздә тотылырга мөмкин.

Тикшерү кәгазьләреннән (контроль сораулар исемлегеннән) файдалану бурычлары барлык яки аерым юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, гражданнарны планлы тикшерү үткәргәндә каралырга, алар тарафыннан файдаланыла торган җитештерү объектларының тибына (аерым характеристикаларына) бәйле булырга мөмкин.

Тикшерү кәгазьләре (контроль сораулар исемлеге) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган гомуми таләпләр нигезендә муниципаль җир контроле органы тарафыннан эшләнә һәм раслана һәм җаваплары юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тикшерү предметын тәшкил иткән мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган сорауларның исемлекләрен үз эченә ала. Муниципаль җир контроленең төре турындагы нигезләмә нигезендә, исемлектә юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга карата куела торган барлык мәҗбүри таләпләргә кагылучы сораулар булырга яисә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт куркынычсызлыгына зыян килү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килүне булдырмау буенча үтәлеше аеруча әһәмиятле булып саналган мәҗбүри таләпләрнең бер өлеше белән планлы тикшерү предметын чикләргә мөмкин.

Берләштерелгән планлы тикшерүләр үткәргәндә, берничә муниципаль контроль органы тарафыннан эшләнә һәм раслана торган җыелма тикшерү кәгазьләре (контроль сораулар исемлеге) кулланылырга мөмкин.

Тикшерү кәгазен (контроль сораулар исемлеген) кулланып тикшерү

үткәргәндә, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына теркәлә.

2.5.2. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карарындагы нормалар һәм таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.5.3. Планнан тыш тикшерү үткәрү предметы булып, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру процессында мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәү тора.

Планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәүдә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы чыгу;

2) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнешсез контроль чаралары нәтиҗәләрен анализлау, муниципаль җир контроле органнарына гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән кергән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны карау яки алдан тикшерү йомгаклары буенча муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затының дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында дәлилләнгән мәгълүмат тапшыру:

а) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян килү куркынычы янау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янау;

б) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

в) хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта,

кулланучыларның хокуклары бозылу.

Үткәрү нигезләре 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 бүлегендәге 2 пункында күрсәтелгән планнан тыш тикшерүдән тыш, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга тикшерү үткәрелә башлаганчы егерме дүрт сәгатьтән ким булмаган вакыт эчендә муниципаль җир контроле органы тарафыннан, теләсә кайсы ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, шундый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элек муниципаль җир контроле органына бирелгән булса, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ ярдәмендә хәбәр ителә.

Муниципаль җир контроле органына мөрәҗәгать итүче затны ачыклау мөмкинлеге булмаган, шулай ук 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 бүлегендәге 2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлар булган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып саналмый. 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 бүлегендәге 2 пункты нигезендә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып саналмаган очракта, муниципаль җир контроле органының вазыйфаи заты, әгәр аңарда мөрәҗәгать яки гаризаның авторлыгында нигезле шикләнүләр булса, мөрәҗәгать иткән затны ачыклау өчен ул тиешле чаралар күрергә тиеш. Электрон документлар рәвешендә җибәргән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, гариза бирүче тарафыннан аның бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри авторизацияне күздә тоткан мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып җибәрелгән очракта, алар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып санала.

Мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны караганда, элек кергән шундый мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга карата элек үткәрелгән контроль чараларның нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат булмаганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары тарафыннан кергән мәгълүматны алдан тикшерү үткәрелә. Алдан тикшерү үткәрү барышында, гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән, мәгълүмат биргән затлардан өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар соратып алу буенча (шул исәптән телдән) чаралар күрелә, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең муниципаль җир контроле органы карамагында булган документларын карап тикшерү үткәрелә, кирәк булганда әлеге затларга мәгълүмат бирү һәм муниципаль җир контроле органы таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнешсез гамәлгә ашырыла торган контроль чаралар үткәрелә. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне алдан тикшерү кысаларында, алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, ләкин андый аңлатмаларны һәм башка документларны бирү

мәҗбүри түгел.

Муниципаль җир контроле органы җитәкчесе карары буенча, тиешле тикшерү башланганнан соң аны оештыруга сәбәп булган мөрәҗәгать яки гаризаның аноним булуы, яисә мөрәҗәгать яки гаризада дөрес булмаган мәгълүматлар барлыгы ачыкланса, ул вакытта алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

Әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә ялган мәгълүматлар күрсәтелгән булса, муниципаль җир контроле органы муниципаль җир контроле органының гражданнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән күрсәтелгән затларның гаризаларын һәм мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле чыгымнарын кайтарып алу турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты, граждан яки аның вәкаләтле вәкиле булмау сәбәпле, яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлекнең фактик гамәлгә ашырылмавы сәбәпле, яисә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының башка төр эш итүләре (эш итмәүләре) сәбәпле планлы яки планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү мөмкин булмаган очракта, муниципаль җир контроле органының вазыйфаи заты, тикшерүне үткәрү мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкин булмау турында акт төзи. Бу очракта, муниципаль җир контроле органы тиешле тикшерүне үткәрү мөмкин булмау турында акт төзегәннән соң өч ай эчендә, планлы тикшерүне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга алдан хәбәр итмичә, шундый юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга карата планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итә.

Планнан тыш тикшерү документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

Муниципаль җир контроле органы тарафыннан юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү федераль законнарда билгеләнгән нигезләрдә, андый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органы белән килешенгәннән соң үткәрелә.

Муниципаль җир контроле органы җитәкчесе, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) имзалаган көнне, аны үткәрүне федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә килешенү максатында, муниципаль җир контроле органы юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турындагы гаризаны тапшыра яисә почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы белән расланган типовой форма нигезендә рәсмиләштерелә). Әлеге гаризага

муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгының яки приказының күчермәсе һәм аны үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә торган документлар теркәлә.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, андый кимчелекләр булу вакытына мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең бозылуы ачыклану торса, кичектергесез чаралар күрү кирәк булу сәбәпле, муниципаль җир контроле органы 24 сәгать эчендә прокуратура органнарына документлар җибәрү юлы белән прокуратура органнарына контроль чаралар үткәрү турында хәбәр итеп, кичемәстән планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә керешергә хокуклы.

Прокурор яки аның урынбасарының планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турындагы яки аны үткәрүне килешенүне кире кагу турындагы карарына карата югарыдагы прокурорга яки судка шикаять бирелергә мөмкин.

2.6. Муниципаль җир контроле үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар.

Муниципаль җир контроле органының муниципаль җир контроле үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеге 2 нче таблицада күрсәтелгән.

2 нче таблица

Муниципаль җир контроле органының муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеге

| Муниципаль җир контроле органының исеме | Вазыйфаның исеме |
|---|---|
| Җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлеге | Бүлек башлыгы<br>Баш белгеч<br>Баш белгеч<br>Әйдәүче белгеч |

2.7. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның мәҗбүри таләпләрне һәм Татарстан Республикасының һәм җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне бозган өчен җаваплылыгы.

Татарстан Республикасының һәм җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез тоткарлык ясый торган, тикшерүләр үткәрүдән качарга тырышкан һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне үтәүдә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында муниципаль җир контроле

органы күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре, гражданнар яки аларның вәкилләре Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.

2.8. Тикшерү үткәргәндә муниципаль җир контроле органы, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгы.

Муниципаль җир контроле органы, аның вазыйфаи затлары, тикшерү үткәргәндә функцияләргә туры килгән вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокуксыз эш иткән (эш итмәгән) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата мондый чаралар күрелгән көннән башлап ун көн эчендә, муниципаль җир контроле органы бу хакта хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга кабул ителгән чаралар турында язма рәвештә хәбәр җибәрергә тиеш.

## 3 бүлек. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга куела торган мәҗбүри таләпләр

Муниципаль җир контролен үткәргәндә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга куела торган үтәлеше контрольдә тотылучы мәҗбүри таләпләр исемлеге, аларны билгеләүче норматив хокукый актлар 3 нче таблицада күрсәтелгән.

3 нче таблица

### Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Эшчәнлекнең төре, күрсәткеч | Мәҗбүри таләпләрнең формулировкасы | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив хокукый актлар |
|---|---|---|
| Муниципаль җир контроле.<br>Планлы (документар һәм күчмә) һәм планнан тыш (документар һәм күчмә) тикшерүләр | Җир участогына оештыру документлары булу; җир участокларын рөхсәтсез биләүне яки алардан билгеләнгән тәртиптә рәсмләштерелгән хокук билгеләүче документлардан башка файдалануны булдырмау тәртибен саклау | РФ Җир кодексының 25, 26 маддәләре, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенең 3 пункты, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |
| | Хокук билгеләүче документлар нигезендә җир участогыннан файдалану (рөхсәт ителгән файдалану) | РФ Җир кодексының 42 маддәсе, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |

| | | |
|---|---|---|
| | Законнар нигезендә җир участокларында урнаштырылган межа, геодезия һәм башка махсус билгеләрне саклау | РФ Җир кодексының 42 маддәсе, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |
| | Җирләрне саклау буенча чараларны, шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру | РФ Җир кодексының 42 маддәсе, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |
| | Җир өчен түләүләрне үз вакытында гамәлгә ашыру | РФ Җир кодексының 42 маддәсе, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |
| | Җир участокларын үз вакытында үзләштерү | РФ Җир кодексының 42 маддәсе, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |
| | Җир участогыннан файдалану хокукын алу тәртибен үтәү | РФ Җир кодексының 42 маддәсе, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |
| | Җир законнарын бозуны бетерү турында күрсәтмәне үтәү | РФ Җир кодексының 42 маддәсе, Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |

## 4 бүлек. Тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тапшырыла торган документлар, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тапшырыла торган документларның, шулай ук шундый документларның формаларын раслаучы норматив хокукый актларның исемлеге 4 нче таблицада күрсәтелгән

4 нче таблица

Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге

| Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ | Документның формасын билгеләүче норматив хокукый акт |
|---|---|
| - тикшерү актын имзалау хокукы белән җирдән файдалану мәсьәләләре буенча мәнфәгатьләрне | РФ Җир кодексы, Административ хокук бозулар |

| | |
|---|---|
| яклауга ышаныч язуы;<br>- паспорт;<br>- милекчелек хокуклары 2000 елга кадәр теркәлгән хокук билгеләүче документлар;<br>- җир участокларының субаренда килешүләре;<br>- график материаллар;<br>- элек булган җир участокларына хокукларны һәм бурычларны сату яки бирү килешүләре | турында РФ кодексы,<br>294-ФЗ санлы Федераль закон,<br>ТР Җир кодексы,<br>Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар исемлеге 5 нче таблицада күрсәтелгән.

5 нче таблица

Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар исемлеге

| Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документ | Документның формасын билгеләүче норматив хокукый акт |
|---|---|
| - Күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>- Күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматлар<br>- Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан мәгълүматлар<br>- Бердәм дәүләт кече һәм урта эшмәкәрлек реестрыннан мәгълүматлар<br>- Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны буенча теркәлүе турында мәгълүматлар | РФ Җир кодексы,<br>Административ хокук бозулар турында РФ кодексы,<br>294-ФЗ санлы Федераль закон,<br>ТР Җир кодексы,<br>Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы |

## 5 бүлек. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр

Муниципаль җир контроле юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне һәм гражданнарны планлы (документар һәм күчмә) һәм планнан тыш (документар һәм күчмә) тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерүнең предметы булып эшчәнлекне гамәлгә ашыру процессында юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү, шулай ук эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерү язуындагы мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә туры килүе тора.

Планнан тыш тикшерү предметы булып эшчәнлекне гамәлгә ашыру

процессында юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлеше, муниципаль җир контроле органы күрсәтмәләренең үтәлеше, гражданнар тормышына, сәламәтлегенә зыян килүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян килүне булдырмау, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү, шундый зыян килү нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар үткәрү тора.

Документар тикшерү предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр документларында аларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган белешмәләр, аларның эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган документлар, тикшерелә торган җир участогына карата гражданнарның хокукларын һәм бурычларын билгели торган һәм алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль җир контроле органнарының күрсәтмәләрен һәм карарларын үтәүгә бәйле документлар тора.

Күчмә тикшерү предметы булып юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне һәм норматив-хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү, җир участогыннан файдалануның хокук билгели торган документларга, максатчан файдалануга, рөхсәт ителгән файдалану төренә, чикләргә һ.б. туры килүе һәм мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча күрелә торган чаралар тора.

Муниципаль функциянең үтәлешен туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

Муниципаль җир контролен үтәүнең административ процедураларының (гамәлләренең) блок-схемасы әлеге Административ регламентка 7 нче кушымтада күрсәтелгән.

5.1. Планлы тикшерү үткәрүнең административ процедуралары.

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру максатларында юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне һәм гражданнарны планлы тикшерүләр үткәрү түбәндәге административ процедураларны күздә тота:

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм гражданны планлы документар тикшерүне үткәрү;

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм гражданны планлы күчмә тикшерүне үткәрү.

5.1.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планлы документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасы.

5.1.1.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм гражданны планлы документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасын башлау өчен тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм гражданны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү нигез булып тора. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм гражданны планлы тикшерүне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән нигездә гамәлгә ашырыла.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм физик затны планлы документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасы түбәндәге

эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

- планлы документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле затларны билгеләү турында карар кабул итү;

- планлы документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкны (приказны) рәсмиләштерү;

- юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм гражданнарга документар тикшерү үткәрү турында хәбәр итү;

- планлы документар тикшерү үткәрү;

- планлы документар тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.1.1.2. Муниципаль җир контроле органы җитәкчесе планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы нигезендә:

- җаваплы башкаручыларны билгели, монда карар кабул итү критерие булып вазыйфаи затның (алга таба – җаваплы башкаручы) юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм гражданны тикшерү үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.6 пункты нигезендә тикшерүләр үткәрүгә вәкаләте булу тора;

- кирәк булган очракта, тикшерү үткәрелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилирланган затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә һәм гражданга хәбәр итү өчен кирәкле вакытны исәпкә алмыйча (хәбәр итүгә исәпләнгән вакыт хәбәр итү алымына бәйле), тикшерү үткәрә башлауга кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмый, яисә турыдан-туры планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы төзегәннән соң.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.1.1.3. Җаваплы башкаручы:

- Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче санлы Приказы белән расланган форма буенча 1 нче кушымтада каралганча юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тикшерү турында боерык (приказ) проектын, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан объектында (объектларында) күзәтчелек буенча чаралар үткәрү буенча җаваплы башкаручыларга план-йөкләмә әзерли;

- боерык (приказ) проектын имзалау өчен муниципаль җир контроле органы җитәкчесенә җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә һәм гражданга хәбәр итү өчен кирәкле вакытны исәпкә алмыйча (хәбәр итүгә исәпләнгән вакыт хәбәр итү алымына бәйле), тикшерү үткәрә башлауга кадәр 5 эш көненнән дә соңрак түгел.

Эш итүнең нәтиҗәсе: муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан имзалаган тикшерү үткәрү турында боерык (приказ).

5.1.1.4. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) күчермәләрен почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәрү юлы белән яки башка уңайлы ысул белән (факсимиль элемтә, электрон почта

аша, алу турында билге куеп кулга тапшыру) тикшерү үткәрү турында хәбәр итә.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм граждан адресына тикшерү үткәрү турында хәбәр җибәрү эш кәгазьләрен алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә язып куела.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрә башлауга кадәр 3 эш көненнән дә соң түгел.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм граждан адресына тикшерү үткәрү турында җибәрелгән боерык (приказ) күчермәсе.

Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзаларын планлы тикшерүне үткәргән очракта, җаваплы башкаручы тикшерү башланганчы 3 эш көне алдан, аның вәкиленең планлы тикшерү үткәргәндә катнашуын яки анда булуын тәэмин итү максатында, үз-үзен җайга салучы оешмага планлы тикшерү үткәрү турында хәбәр бирә.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм граждан 10 эш көне эчендә муниципаль җир контроле органына тикшерү үткәрү турындагы боерык (приказ) күчермәсендә күрсәтелгән документларны, мөһер (ул булганда) белән расланган һәм вәкаләтле вәкилнең, җитәкченең, башка вазыйфаи затның, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның имзасы куелган күчермә рәвешендә җибәрергә тиеш.

Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, документлар күчермәләренең нотариаль раслануын таләп итүгә юл куелмый.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан запроста күрсәтелгән документларны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, электрон документлар рәвешендә җибәрергә хокуклы.

5.1.1.5. Документар тикшерү үткәрү процессында җаваплы башкаручылар тарафыннан иң беренче чиратта, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның билгеләнгән тәртиптә муниципаль җир контроле органы карамагына тапшырылган документлары, элекке тикшерүләрнең актлары, административ хокук бозулар турында һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга карата элек гамәлгә ашырылган тикшерүләрнең нәтиҗәләре турындагы башка документлар карала.

5.1.1.6. Җаваплы башкаручы, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның документларын карап тикшерү нәтиҗәләре нигезендә, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан адресына хат (дәлилле запрос) җибәрү (җибәрмәү) турында карар кабул итә. Мәгълүматларның дөреслеге карар кабул итүнең критерие булып санала. Әгәр документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырса яисә әлеге мәгълүматлар мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү мөмкинлеге бирмәсә, хаталар һәм (яки) каршылыклар, муниципаль җир контроле органына бирелгән һәм анда булган мәгълүматлар тәңгәл килмәү ачыкланса, ул очракта җаваплы башкаручы:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан адресына мәгълүматларны бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны һәм 10 эш көне эчендә язма

рәвештә тиешле аңлатмаларны яисә карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру турында дәлилләнгән запрос белән хат әзерли;

- имзалау өчен муниципаль җир контроле органына хат җибәрә;

- имзаланганнан соң, җитәкченең тикшерү үткәрү турында мөһер белән расланган боерык күчермәсе белән бергә дәлилләнгән запросны (хатны) юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан адресына почта аша аны тапшыру турындагы белдерү кәгазе булган заказлы хат яисә башка уңайлы юл белән (факсимиль элемтә, электрон почта, алу турында билге куеп кулга тапшыру) җибәрә.

Хатны, дәлилләнгән запросны җибәрү эш кәгазьләрен алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә язып куела.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрелә башлаганчы 5 эш көне эчендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм граждан адресына карау өчен кирәкле булган башка документларны тапшыру турында җибәрелгән хат (дәлилләнгән запрос).

5.1.1.7. Әгәр бирелгән аңлатмаларны һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаганда мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, муниципаль җир контроле органы бу очракта күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

Күчмә тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм гражданнан документар тикшерү барышында тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итү тыела.

Күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарны җитәкче аны җаваплы башкаручы тарафыннан үткәрү кирәклеген дәлилләүне исәпкә алып кабул итә. Күчмә тикшерү үткәрү кирәклеге турындагы карарны кабул итү критерие булып юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны карап тикшерү барышында ачыкланган күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт иткән мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләре булу тора.

Күчмә тикшерү (аны үткәрү турында карар кабул ителгәндә) әлеге Регламентның 5.1.2 пунктында күрсәтелгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәү срогы: алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап 5 эш көне эчендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тапшырылган һәм җаваплы башкаручы тарафыннан карап тикшерелгән аңлатмалар һәм (яки) документлар; кирәк булганда күчмә тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) проекты.

5.1.1.8. Җаваплы башкаручы планлы документар тикшерү нәтиҗәләре буенча ике нөсхәдә 2 нче кушымтада каралганча (тикшерү актының типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы белән расланган) юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тикшерү актын төзи.

Мәҗбүри таләпләргә, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән

таләпләргә контроль чаралары үткәрү нәтиҗәсендә кимчелекләр ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнар үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән (ачыкланган кимчелекләр нәтиҗәсендә килгән зыянны каплау) түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- тикшерү актында кимчелекләр ачыкланган барлык очракны язып куя;

- ачыкланган кимчелекләрне бетерү срокларын күрсәтеп, аларны бетерү турында һәм (яки) кешеләр тормышына, сәламәтлегенә зыян килүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян килүне, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян килүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль мөлкәткә зыян килүне булдырмау буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар үткәрү турында тикшерү актына кушымта булып торган (һәр кимчелек буенча аерым күрсәтмә) һәм үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмә бирә, һәм әлеге Регламентта каралган тәртиптә, күрсәтелгән күрсәтмәләрнең билгеләнгән срокларда үтәлешен контрольдә тота.

- Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары буенча административ һәм башка җаваплылык каралган җир законнары таләпләрен бозулар ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә чаралар күрү өчен, тикшерү актын дәүләт җир күзәтчелеге органына җибәрә.

Әгәр контроль чаралар барышында контроль чаралар үткәрү объекты булып торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең закон таләпләрен бозып гамәлгә ашырылуы билгеле булса һәм аларны ачыклау, булдырмый калу һәм юл куймау мәсьәләләре муниципаль җир контроле органы компетенциясенә карамаган очракта, муниципаль җир контроле органы андый кимчелекләр турындагы мәгълүматны (мәгълүматларны) Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнарына җибәрергә тиеш.

Җаваплы башкаручы тикшерү актының (кушымталары белән бергә) бер нөсхәсен делога тегеп куя, икенчесен (кушымталары белән бергә) тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турындагы расписка белән җитәкчегә, юридик затның башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, гражданга яки аның вәкиленә тапшыра.

Җитәкче, юридик затның башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, граждан яки аның вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәрелә һәм делода саклана торган акт нөсхәсенә теркәп куела.

Үтәү срогы:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү башланганнан соң 20 көн

эш көненнән дә соңга калмый;

- тикшерү актын заказлы хат белән җибәрү: контроль чаралар тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән, аларның берсе юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе делога тегеп куелган тикшерү акты.

5.1.1.9. Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы, тикшерү тәмамланган көннән башлап 3 эш көне эчендә, үз-үзен җайга салучы оешмага ачыкланган кимчелекләр турында хәбәр итә.

5.1.2. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планлы күчмә тикшерүне үткәрү» административ процедурасы.

5.1.2.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планлы күчмә тикшерүне үткәрү» административ процедурасын башлау өчен тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны муниципаль җир контроле органының планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү, шулай ук планлы документар тикшерү (әлеге Регламентның 5.1.1.7 пункты) нәтиҗәсе булып саналган планлы күчмә тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) нигез булып тора, әгәр планлы документар тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр, гражданның муниципаль җир контроле органы боерыгы документларындагы мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

- тиешле контроль чаралар үткәрмичә, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү.

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планлы күчмә тикшерүне үткәрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.1.1.1 пунктында күрсәтелгән эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.1.2.2. Җаваплы башкаручыны, экспертларны билгеләү, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планлы тикшерүне үткәрү турындагы боерыкны (приказны) әзерләү, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданга планлы тикшерү үткәрү турында хәбәр итү әлеге Регламентның 5.1.1.2 - 5.1.1.4 пунктчаларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.1.2.3. Җаваплы башкаручы, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан объектына килгәч, тикшерүне түбәндәгечә башлыйлар:

- хезмәт таныклыгын күрсәтәләр;

- җитәкчене яки юридик затның башка вазыйфаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, гражданны яки аның вәкилен муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгы (приказы) белән мәҗбүри рәвештә таныштыралар;

- җитәкчене яки юридик затның башка вазыйфаи затын, шәхси

эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, гражданны яки аның вәкилен күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре, шулай ук күчмә тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль чараларның төрләре һәм күләмнәре, күчмә тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертлар, эксперт оешмалар вәкилләренең составы, аны үткәрү сроклары һәм шартлары белән мәҗбүри рәвештә таныштыралар.

Җаваплы башкаручы түбәндәге контроль чараларны үткәрә:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли;

- планлы күчмә тикшерү актын тутыра.

Планлы күчмә тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлмәве ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

- кимчелекләр ачыкланган барлык очракны тикшерү актына язып куя;

- ачыкланган кимчелекләрне бетерү срокларын күрсәтеп, аларны бетерү турында һәм (яки) кешеләр тормышына, сәламәтлегенә зыян килүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян килүне, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян килүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль мөлкәткә зыян килүне булдырмау буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр бирә. Күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора (һәр кимчелек буенча аерым күрсәтмә чыгарыла);

- мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән юридик зат хезмәткәрләренең, шәхси эшмәкәрнең, шулай ук гражданнарның аңлатмаларын соратып ала.

Үтәү срогы: юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планлы тикшерүне үткәрүнең гомуми срогы - 20 эш көненнән артык түгел.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү максатында муниципаль җир контроле буенча үткәрелгән чаралар.

5.1.2.4. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.1.1.8 пунктында күрсәтелгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җаваплы башкаручы тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән тикшерү турында, муниципаль җир контроле органының исеме, тикшерү үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләре, бурычлары, максатлары һәм тикшерү предметы, ачыкланган кимчелекләр һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы мәгълүматларны язып куюны гамәлгә ашыра, шулай ук тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфаларын, аның яки аларның имзаларын күрсәтә.

5.1.2.5. Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга

салучы оешмага ачыкланган кимчелекләр турында тикшерү тәмамланган көннән башлап 3 эш көнендә хәбәр җибәрә.

5.2. Планнан тыш тикшерү үткәрүнең административ процедуралары.

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру максатында юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, гражданнарны планнан тыш тикшерүләрне үткәрү түбәндәге административ процедураларны күздә тота:

- юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, гражданнарны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү;

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү.

5.2.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасы.

5.2.1.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.5.3 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасы түбәндәге эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

- шундый юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органнары белән килешенү;

- планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү турында карар кабул итү;

- планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) рәсмиләштерү;

- планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

- планнан тыш документар тикшерүнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.2.1.2. Муниципаль җир контроле органы җитәкчесе, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.5.3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгәндә, бүлекчә җитәкчесенә планнан тыш документар тикшерүне оештыру һәм үткәрү турында йөкләмә бирә.

Бүлекчә җитәкчесе:

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тикшерүне үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгели;

- кирәк булган очракта, тикшерү үткәрелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилирланган затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү срогы: планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгәннән башлап 5 эш көне эчендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тикшерүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручыны билгеләү.

5.2.1.3. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планнан тыш тикшерүне үткәрү турындагы боерыкны (приказны) әзерләү, әлеге Регламентның 5.1.1.3 пункты нигезендә, юридик затны, шәхси эшмәкәрне,

гражданны планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгеләгән көндә гамәлгә ашырыла.

5.2.1.4. Планнан тыш документар тикшерүне үткәрү өчен нигез булып 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 бүлегендәге 2 пунктның «а», «б» пунктчаларында саналган нигезләр торган очракта, җаваплы башкаручы:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына юридик затка, шәхси эшмәкәрне планнан тыш документар тикшерү үткәрүне килешенү турында гариза әзерли һәм аңа муниципаль җир контроле органы җитәкчесеннән имза куйдыра;

- юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына, кулга тапшыру, почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат яки электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш документар тикшерүе үткәрүне килешенү турында гариза җибәрә.

Гаризага планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документлар теркәлә.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш документар тикшерүне үткәрү турында боерык (приказ) имзаланган көнне.

Эш итүнең нәтиҗәсе: прокуратура органына җибәрелгән планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында гариза.

Әгәр планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен нигез булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, андый кимчелекләр булу вакытына мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыклану торса, кичектергесез чаралар күрү кирәк булу сәбәпле, муниципаль җир контроле органы 24 сәгать эчендә прокуратура органына гариза, планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) күчермәләрен һәм аны үткәрү өчен нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документларны җибәрү юлы белән планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында хәбәр итеп, кичекмәстән планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә керешергә хокуклы.

5.2.1.5. Җаваплы башкаручының юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан документларындагы мәгълүматларны бәяләү, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан адресына хат (нигезле запрос) әзерләү, тапшырылган документлардагы кимчелекләргә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның аңлатмаларын карап тикшерү буенча эшләре әлеге Регламентның 5.1.1.5 - 5.1.1.7 пунктчалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.1.6. Тикшерү акты төзү, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тикшерү акты (аларны рәсмиләштерү кирәк булганда кушымталары белән) белән таныштыру әлеге Регламентның

5.1.1.8 пунктчасында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Элек ачыкланган закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәнең үтәлешен тикшергәндә административ хокук бозулар турында эш кузгату өчен муниципаль җир контроле органының законлы күрсәтмәсен срогында үтәмәү, шулай ук Административ хокук бозулар турындагы РФ кодексының 19.5, 19.6 маддәләрендә каралган административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрмәү нигез булып тора.

Кабат ачыкланган кимчелекләр, шулай ук системалы характерга ия кимчелек фактлары мәҗбүри тәртиптә язып куела.

5.2.2. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү» административ процедурасы.

5.2.2.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.5.3 пунктчасында күрсәтелгән очраклар, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмау нигез булып тора:

- муниципаль җир контроле органы боерыгында булган юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан документларындагы мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

- муниципаль җир контроле буенча тиешле чаралар үткәрмичә, юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.1.1.1 пунктчасында күрсәтелгән эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.2. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гранданны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгеләү, эксперт оешмалар вәкилләрен җәлеп итү әлеге Регламентның 5.2.1.2 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.3. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында боерык (приказ) әзерләү әлеге Регламентның 5.1.1.3 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.4. 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 бүлегендәге 2 пунктның «а», «б» пунктчаларында саналган нигезләр планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү өчен нигез булган очракта, җаваплы башкаручы:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында гариза әзерли һәм аңа муниципаль җир контроле органы җитәкчесеннән имза куйдыра;

- юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына, кулга тапшыру, почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат яки көчәйтелгән электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү

турында гариза җибәрә.

Гаризага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (приказның) күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булып торучы мәгълүматларны үз эченә алган документлар теркәлә.

Үтәү срогы: юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында боерык (приказ) имзаланган көнне.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында прокуратура органына җибәрелгән гариза.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, андый кимчелекләр булу вакытына мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыклану торса, кичектергесез чаралар күрү кирәк булу сәбәпле, муниципаль җир контроле органы 24 сәгать эчендә прокуратура органына гариза, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) күчермәләрен һәм аны үткәрү өчен нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документларны җибәрү юлы белән планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында хәбәр итеп, кичекмәстән планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә керешергә хокуклы.

5.2.2.5. Үткәрү нигезләре 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 бүлегендәге 2 пункында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга тикшерү үткәрелә башлаганчы 24 сәгатьтән ким булмаган вакытта муниципаль җир контроле органы тарафыннан, теләсә кайсы ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, шундый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан элек муниципаль җир контроле органына бирелгән булса, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ ярдәмендә хәбәр ителә.

Әгәр юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян килгән, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян килгән, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан яки чыгарга мөмкин булган очракта, юридик затка, шәхси эшмәкәрләргә планнан тыш күчмә тикшерү башлану турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзаларын планнан тыш күчмә тикшерүне үткәргән очракта, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага аның вәкиленең планнан тыш күчмә тикшерү үткәргәндә

катнашуын яки анда булуын тәэмин итү максатында, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында хәбәр итә.

5.2.2.6. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү әлеге Регламентның 5.1.2.3 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.7. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.1.1.8 һәм 5.1.2.4 пунктчалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органы белән килешенү буенча гамәлгә ашырылган булса, тикшерү актының күчермәсе, тикшерү акты төзелгән көннән башлап биш эш көне эчендә прокуратура органына җибәрелә.

Элек ачыкланган закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшергәндә, административ хокук бозулар турында эш кузгату максатында дәүләт күзәтчелеге органнарына материаллар җибәрү өчен муниципаль җир контроле органының законлы күрсәтмәсен срогында үтәмәү, шулай ук Административ хокук бозулар турындагы РФ кодексының 19.5, 19.6 маддәләрендә каралган административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрмәү нигез булып тора.

Кабат ачыкланган кимчелекләр, шулай ук системалы характерга ия кимчелек фактлары мәҗбүри тәртиптә язып куела.

5.2.2.8. Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага ачыкланган кимчелекләр турында планнан тыш күчмә тикшерү тәмамланган көннән башлап 3 эш көне эчендә хәбәр итә.

5.3. Тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибен билгеләүче 294-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләре производствода аварияләр, бәхетсезлек очраклары килеп чыгу, кешеләрнең, хайваннарның һәм үсемлекләрнең йогышлы һәм массакүләм йогышлы булмаган авырулары (агуланулары, зарарланулары), әйләнә-тирә мохиткә, гражданнар һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зыян китерү сәбәпләрен тикшергәндә кулланылмый.

## 6 бүлек. Муниципаль функцияне үтәүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

6.1. Муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларның хезмәт бурычлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра, тикшерүләр үткәрү барышында вазыйфаи затларның үз вәкаләтләрен тиешенчә башкармау очракларының исәбен алып бара, тиешле тикшерүләр үткәрә һәм вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тоту муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.3. Әлеге Регламент нигезендә муниципаль җир контролен үтәү буенча гамәлләрнең сроклары, эзлеклелеге үтәлешенә, муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының карарлар кабул итүенә агымдагы контроль муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары

тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.4. Муниципаль җир контроле органының муниципаль функцияне үтәүгә агымдагы контрольне, әлеге контрольне гамәлгә ашыру тәртибен һәм аның периодик рәвештә кабатланып торуын тормышка ашыруга вәкаләтле хезмәткәрләр исемлеге муниципаль җир контроле органы актлары белән билгеләнә. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыруга муниципаль җир контроле органы хезмәткәрләренең вәкаләтләре муниципаль җир контроле органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрендә билгеләнә.

6.5. Муниципаль җир контроле органының муниципаль функцияне үтәү тулылыгына һәм сыйфатына контроль планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне, тикшерелә торган затларның хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) кызыксынган затларның мөрәҗәгатьләрен карау, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүгә контрольне дә үз эченә ала.

Тикшерүләр муниципаль җир контроле органы җитәкчесе боерыгы (приказы) нигезендә үткәрелә. Тикшерүләрнең нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда муниципаль функцияне үтәгәндә җитешсезлекләр булмау яисә ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр язып куела.

6.6. Муниципаль функцияне үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы тикшерүләр муниципаль җир контроле органының агымдагы елга тикшерүләренең еллык планына туры китереп үткәрелә. Планлы тикшерүләр муниципаль функцияне үтәү компетенциясенә кергән муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан күрсәтелгән планга кертелә.

6.7. Муниципаль функцияне үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерүләр муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияне үтәгәндә кабул ителгән яки гамәлгә ашырылган карарларына яки эш итүләренә (эш итмәүләренә) гражданнарның шикаятьләре (дәгъвалары) нигезендә үткәрелә.

6.8. Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияне үтәгәндә җибәргән кимчелекләре ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрелә.

6.9. Муниципаль җир контроле органының муниципаль функцияне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлары муниципаль функцияне үтәү барышында кабул ителгән яки гамәлгә ашырылган карарларына яки эш итүләренә (эш итмәүләренә) җаваплы санала.

Муниципаль җир контроле органы вәкаләтле затларының җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә, аларның вазыйфаи инструкцияләре белән ныгытыла.

6.10. Иҗтимагый җир контроле җирләрдән файдалану һәм аларны

саклау өлкәсендәге законнарны үтәү һәм закон бозуларны кисәтү буенча һәркемнең хокукын тормышка ашыру максатында гамәлгә ашырыла. Иҗтимгый җир контроле җәмәгать берләшмәләре һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмалар, аларның уставлары нигезендә, шулай ук законнар нигезендә гражданнар тарафыннан гамәлгә ашырыла. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган иҗтимагый җир контроле нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

## 7 бүлек. Муниципаль функцияне үтәүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

7.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, граждан яки аның вәкиле, башка кызыксынган затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) муниципаль җир контроле органы, аның вазыйфаи затлары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерү вакытында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның хокуклары бозылуга юл куелса, муниципаль җир контроле органы, аның вазыйфаи затларының муниципаль функцияне үтәү барышында эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукына ия.

7.2. Муниципаль җир контроле органының, аның вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияне үтәү барышында кабул иткән яки гамәлгә ашырган карарлары яки эш итүләре (эш итмәүләре) тора.

7.3. Аларның компетенциясе чикләрендә муниципаль җир контроле органына яки вазыйфаи затка кергән шикаять мәҗбүри рәвештә карап тикшерелергә тиеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүне кире кагу яки туктатып тору өчен сәбәпләр каралмаган.

7.4. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми:

- әгәр язмача шикаятьтә шикаять белән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә законга каршы әзерләнгән, эшләнә торган яки эшләнгән эшләр, шулай ук аны әзерләүче, эшләүче яки эшләгән зат турында мәгълүматлар булса, шикаять аның компетенциясе чикләрендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш);

- әгәр шикаятьтә цензуралы булмаган яки кимсетүле сүзләр, муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса (муниципаль җир контроле органының вазыйфаи заты шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хокукны явыз ниятта файдалану рөхсәт ителмәү турында хәбәр итәргә хокуклы);

- әгәр язмача шикаять тексты укырлык булмаса (күрсәтелгән шикаять шулай ук карап тикшерү өчен аларның компетенциясе чикләрендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш түгел), бу хакта шикаять теркәлгән көннән башлап җиде көн эчендә шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), почта адресы укырлык дәрәҗәдә булса;

- әгәр гариза бирүченең шикаятендә аның элек җибәрелгән шикаятьләренә берничә тапкыр нигезле җаваплар бирелгәннән соң да шикаятьтә яңа хәбәрләр яки хәлләр китерелмәгән сорау булса (әлеге шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк җирле үзидарә органына яки бер үк вазыйфаи затка юлланган булса, (шикаять җибәрүчегә язышуны туктату карары турында хәбәр ителә);

- әгәр шикаятьтә куелган сорау буенча нигезле җавап дәүләт яки башка федераль закон белән саклануучы сер булган мәгълүматларны таратмыйча бирелә алмаса (шикаять җибәрүчегә анда куелган сорауга күрсәтелгән мәгълүматларны тарату ярамау сәбәпле, нигезле җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә).

7.5. Муниципаль җир контроле органының, аның вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып муниципаль җир контроле органына шәхсән гариза бирүчедән (гариза бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) яки почта аша, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән муниципаль җир контроле органының рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә шикаять керү тора.

7.6. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы. Әлеге төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар муниципаль җир контроле органы адресына язма рәвештә тиешле запрос җибәрергә тиеш. Җитәкче, җаваплы башкаручылар, запрос теркәлгән көннән башлап утыз календарь көн эчендә, соралган мәгълүматларны һәм документларны бирергә тиеш.

7.7. Муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять муниципаль җир контроле органы җитәкчесенә җибәрелергә мөмкин. Муниципаль җир контроле органының һәм муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең эш итүләре (эш итмәүләре) буенча шикаять Башкарма комитетка җибәрелергә мөмкин.

7.8. Муниципаль җир контроле органына яки муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затына, аларның компетенциясе чикләрендә кергән шикаять, ул теркәлгән көннән башлап 30 календарь көннән артмаган срокта карап тикшерелә.

Җирле үзидарә органы яки вазыйфаи зат, шикаятьне карап тикшерүче җирле үзидарә органының яки вазыйфаи затның билгеләнгән тәртиптә җибәрелгән запросы буенча шикаятьне карап тикшерү өчен кирәкле

документларны һәм материалларны 30 календарь көн эчендә бирергә тиеш (дәүләт яки башка федераль закон белән саклanучы сер булган мәгълүматларга ия һәм аларны бирүнең аерым тәртибе билгеләнгән документлардан һәм материаллардан тыш).

Аерым очракларда, шулай ук әлеге пунктта күрсәтелгән запрос җибәрелгән очракта вазыйфаи зат яисә шуңа вәкаләтле зат, шикаятьне җибәрүчегә аны карап тикшерү срогы озайтылу турында хәбәр итеп, шикаятьне карап тикшерү срогын 30 календарь көннән артмаган срокка озайтырга мөмкин.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль функцияне үтәү барышында эш итүләргә (эш итмәүләргә) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, атап әйткәндә:

- тикшерү барышында җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, аларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чара күрү;

- Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуда гаепле җаваплы башкаручыларга карата күрелгән чаралар турында, шундый чаралар күрелгән көннән башлап 10 көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга язма рәвештә хәбәр итү;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга әлеге карарның дәлилләнгән нигезле булуын язма рәвештә хәбәр итеп, муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда эш итүләргә (эш итмәүләргә) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру.

Шикаятькә җавап муниципаль җир контроле органына яки вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә һәм муниципаль җир контроле органына яки вазыйфаи затка язма рәвештә кергән шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә. Моннан тыш, билгесез даирә затларының мәнфәгатьләренә кагылышлы тәкъдимнәрне, гаризаны яки шикаятьне үз эченә алган, муниципаль җир контроле органына яки вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатькә, аерым алганда билгесез даирә затларына карата чыгарылган суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибенә аңлатма биреп, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль законның 6 маддәсенең 2 бүлегендәге таләпләрне үтәп «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль җир контроле органының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

7.10. Муниципаль җир контроле органы шикаятьне карап тикшерү өчен, мөрәҗәгать итүчедән муниципаль җир контроле органы вазыйфаи

затларының нигезсез эш итүләрен раслаучы беренчел документларны, шул исәптән электрон рәвештә соратып алырга хокуклы.

Соралган материаллар мөрәҗәгать итүче тарафыннан запрос кергән датадан башлап 30 календарь көн эчендә бирелергә тиеш.

7.11. Муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләре (эш итмәүләре) нәтиҗәсендә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә китерелгән зыян Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә урынсыз дип табылса, гражданнар законнары нигезендә, килми калган файданы (алынмаган табышны) да кертеп, тиешле бюджет акчалары хисабына кире кайтарылырга тиеш.

7.12. Муниципаль җир контроле органының, аның вазыйфаи затларының хокуксыз эш итүләре (эш итмәүләре) белән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга китергән зыян күләмен билгеләгәндә, шулай ук юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның продукция (эшләр, хезмәтләр) үзкыйммәтенә яки хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар юридик яки башка профессиональ ярдәм алу өчен гамәлгә ашырган яки гамәлгә ашырырга тиешле эшчәнлекләренең финанс нәтиҗәләренә һәм чыгымнарына кагылышлы чыгымнары исәпкә алына.

7.13. Муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының хокуклы эш итүләре белән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга китергән зыян, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, түләтелергә тиеш түгел.

7.14. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләреннән риза булмыйча, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирелергә мөмкин.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен
гамәлгә ашыруның
административ регламентына
1 нче кушымта

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(җирле үзидарә органының яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән

______________________________________________________________

______________________________________________________________

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органның исеме)

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны
______________________________ тикшерүне үткәрү турында
(планлы/планнан тыш, документар/күчмә)
муниципаль җир контроле органының
_____елның «___» ___________ № ____
БОЕРЫГЫ (ПРИКАЗЫ)

1. ___________________________________________________________
(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең,

______________________________________________________________

гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)

______________________________________карата тикшерү үткәрергә.

2. Урнашу урыны: ______________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(юридик затның (филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең), шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан эшчәнлекне фактик гамәлгә ашыру һәм (яки) алар тарафыннан файдаланыла торган производство объектларының урыннары)

3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле зат(лар) итеп билгеләргә: _________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(тикшерү үткәргән вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы)

4. Түбәндәге затларны экспертлар, эксперт оешмаларның вәкилләре буларак тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә: ______________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(тикшерү үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы һәм/яки аккредитация турында таныклык реквизитларын һәм таныклыкны биргән аккредитация буенча органның исемен күрсәтеп, эксперт оешманың исеме)

5. Әлеге тикшерү ______________________________________________
(муниципаль җир контроле төренең исеме,

_______________________________________________________________________________

«Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) реестры» федераль дәүләт

_______________________________________________________________________________

мәгълүмат системасында функциянең(ләрнең) реестр номеры(лары)

__________________________________________________ кысаларында үткәрелә.

6. Әлеге тикшерүнең ___________________________________________________

_______________________________________________________________________

__________________________________________ максатында үткәрелүен билгеләргә.

Үткәрелә торган тикшерүнең максатларын билгеләгәндә түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:

а) планлы тикшерү үткәрелгән очракта:

- планлы тикшерүләр үткәрүнең расланган еллык планына сылтама;

- әгәр планлы тикшерү үткәргәндә тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) кулланылырга тиеш булса, тикшерү кәгазе реквизитлары (контроль сораулар исемлеге);

б) планнан тыш тикшерү үткәрелгән очракта:

- тикшерелә торган затка ачыкланган җитешсезлеген бетерү турында элек бирелгән, үтәлү срогы чыккан күрсәтмәнең реквизитлары;

- әгәр юридик затны, шәхси эшмәкәрне тиешле планнан тыш тикшерүне үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү, рөхсәт бирү (килешенү) кагыйдәләрендә каралган булса, юридик заттан яки шәхси эшмәкәрдән хокукый статус, эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыру хокукына махсус рөхсәт (лицензия) яки башка юридик әһәмиятле эшләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт (килешенү) бирү турында гариза реквизитлары;

- муниципаль җир контроле органнарына гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларның реквизитлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүмат турында мәгълүматлар;

- муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затының юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнешсез контроль чараларның йомгакларын анализлау, муниципаль җир контроле органнарына гражданнардан, шул исәптән, шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматларны карап тикшерү яки алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилле күрсәтмәсе реквизитлары;

- законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе реквизитлары һәм таләпләргә теркәлә торган материаллар һәм мөрәҗәгатьләрнең реквизитлары;

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнешсез контроль чаралары үткәрү барышында мәҗбүри таләпләрнең бозылу куркынычы ачыкланган индикаторлар турында мәгълүматлар;

в) прокуратура органнары тарафыннан килешенергә тиешле, ләкин кичектергесез чаралар күрү максатларында планнан тыш күчмә тикшерү үткәрелгән очракта, әгәр зыян китерү яисә таләпләрне бозу аны кылган вакытта турыдан-туры ачыкланса, зыян китерүгә яисә тикшерелә торган таләпләрне бозуга бәйле рәвештә ул кичекмәстән үткәрелергә тиеш:

- кимчелекне ачыклаган вазыйфаи зат тарафыннан тапшырылган һәм тикшерү үткәрү турындагы боерыкка (приказга) теркәлә торган документ (рапорт, доклад язмалары һәм башкалар) күчермәсенең реквизитлары;

әлеге тикшерүнең бурычлары булып ______________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________ тора.

7. Әлеге тикшерүнең предметы булып түбәндәгеләр тора (кирәклесенең астына сызарга):

мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү;

эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдә булган мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә туры килүе;

әгәр юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тиешле планнан тыш тикшерүне үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү, рөхсәт бирү (килешенү) кагыйдәләрендә каралган булса, юридик заттан, шәхси

эшмәкәрдән, гражданнан хокукый статус, эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыру хокукына махсус рөхсәт (лицензия) яки башка юридик әһәмиятле эшләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт (килешенү) бирү турында гаризадагы һәм документлардагы мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә, шулай ук күрсәтелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр турында бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында һәм башка федераль мәгълүмат ресурсларындагы мәгълүматларга туры килүе;

муниципаль җир контроле органнарының күрсәтмәләрен үтәү;

түбәндәге чараларны үткәрү:

гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян китерүне булдырмау буенча;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү буенча;

дәүләт иминлеген тәэмин итү буенча;

андый зыян килүнең нәтиҗәләрен бетерү буенча.

8. Тикшерүне үткәрү срогы: ________________________________________

20___ елның «__ _» __________ тикшерүне үткәрергә керешергә.

Тикшерү үткәрүне 20___ елның «___» __________ соңга калмый тәмамларга.

9. Тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре: ____________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

(тикшерү үткәргәндә нигезләнә торган норматив хокукый акт нигезләмәләренә сылтама)

10. Тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

11. Тикшерү барышында тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле булган түбәндәге контроль чараларны үткәрергә (контроль чараның исемен һәм аны үткәрү срокларын күрсәтеп):

1) ____________________________________________________________

2) ____________________________________________________________

12. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында нигезнамәләр, муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар (булган очракта) исемлеге:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

____________________________________________________________

(исемнәрен, номерларын һәм аларны кабул итү даталарын күрсәтеп)

13. Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тапшырырга кирәкле документларның исемлеге:

____________________________________________________________

____________________________________________________________

_______________________________________

_______________________________________

(тикшерү үткәрү турында боерык яки приказ чыгарган муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

_____________________________________

(мөһер белән расланган имза)

____________________________________________________________

____________________________________________________________

(боерык (приказ) проектын турыдын-туры әзерләгән вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) һәм вазыйфасы, элемтә телефоны, электрон адресы (булганда))

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен
гамәлгә ашыруның
административ регламентына
2 нче кушымта

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(җирле үзидарә органының яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органның исеме)

_________________________ _________________________
(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)

_________________________
(актны төзү вакыты)

**Муниципаль җир контроле органы тарафыннан**
**юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны**
**ТИКШЕРҮ АКТЫ**
**№ ______**

_______________________________________________адресы (адреслары) буенча
(тикшерү үткәрү урыны)
______________________________________________________________________
_______________________________________________________________ нигезендә
(реквизитлары (номеры, датасы) күрсәтелгән документның төре
______________________________________________________________________
_______________________________________________________________ карата
(юридик типның исеме, шәхси эшмәкәрнең, гражданның фамилиясе, исеме,
атасының исеме (соңгысы - булганда)
__________________________________________________ тикшерү үткәрелде.
(планлы/планнан тыш, документар/күчмә)

Тикшерүне үткәрү датасы һәм вакыты:
«_____» ________________ ______ ел. ___ сәг. __ минуттан ___ сәг. __ минутка кадәр.
Дәвамлылыгы ______.
«_____» ________________ ______ ел. ___ сәг. __ минуттан ___ сәг. __ минутка кадәр.
Дәвамлылыгы ______.
(юридик затның филиалларын вәкиллекләрен, аерымланган структур бүлекчәләрен тикшергән очракта яки шәхси эшмәкәр берничә адрес буенча эшчәнлек алып барган очракта тутырыла)
Тикшерүнең гомуми дәвамлылыгы: ______________________________.
(эш көннәре/сәгатьләре)

Акт төзелде:

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

(муниципаль җир контроле органының исеме)

Тикшерү үткәрү турындагы боерык/приказ күчермәсе белән таныштым (таныштык):

(күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла) ______________________________

______________________________________________

(фамилия, инициаллар, имза, дата, вакыты)

Тикшерү үткәрүне килешенү турында прокурор (аның урынбасары) карарының датасы һәм номеры:

______________________________________________

______________________________________________

(тикшерүне прокуратура органнары белән килешенү кирәк булган очракта тутырыла)

Тикшерү үткәргән зат (лар):

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

(тикшерү үткәргән вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы; тикшерүдә катнашуга экспертлар, эксперт оешмалар җәлеп ителгән очракта экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы һәм/яки аккредитация турында таныклык реквизитларын һәм таныклыкны биргән аккредитация буенча органның исемен күрсәтеп, эксперт оешмаларның исемнәре)

Тикшерү үткәргәндә катнаштылар:

______________________________________________

______________________________________________

(тикшерү үткәргән вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы; тикшерүдә катнашуга экспертлар, эксперт оешмалар җәлеп ителгән очракта экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфалары һәм (яки) аккредитация турындагы таныклык реквизитларын, аккредитация буенча таныклык биргән органның исемен күрсәтеп, эксперт оешмаларның исемнәре)

Тикшерү үткәрү барышында:

мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланды ((норматив) хокукый актлар нигезләмәләрен күрсәтеп): ______________________________

______________________________________________

(кимчелекләрнең характеры, аларга юл куйган затлар күрсәтелә)

эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдәге мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә ((норматив) хокукый актлар нигезләмәләрен күрсәтеп) туры килмәве ачыкланды:

______________________________________________

______________________________________________

муниципаль җир контроле органнарының күрсәтмәләрен (бирелгән күрсәтмәләрнең реквизитларын күрсәтеп) үтәмәү фактлары ачыкланды:

______________________________________________

кимчелекләр ачыкланмады:

______________________________________________

Муниципаль җир контроле органнары тарафыннан үткәрелгән юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүләрне исәпкә алу журналына язып куелды (күчмә тикшерү вакытында тутырыла):

_________________________ ___________________________________________

(тикшерүче имзасы) (юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең имзасы)

Муниципаль җир контроле органнары тарафыннан үткәрелгән юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүләрне исәпкә алу журналы юк (күчмә тикшерү вакытында тутырыла):

__________________________ __________________________________________

(тикшерүче имзасы) (юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең имзасы)

Актка теркәлгән документлар: _____________________________________________

Тикшерү үткәргән затларның имзалары:

______________________ ________________________

(имза)

Тикшерү акты белән таныштым, барлык кушымталары белән акт күчермәсен алдым:

________________________________________________

________________________________________________

(җитәкченең, башка вазыйфаи затның яки юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, гражданның яки аның вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы)

«____» __________________ ______ ел. _______________

(дата) (имза)

Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында билге: ___________________

(тикшерү үткәргән вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) имзасы)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен
гамәлгә ашыруның
административ регламентына
3 нче кушымта

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(җирле үзидарә органының яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органның исеме)

______________________________ ______________________________

(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)

______________________________

(актны төзү вакыты)

Муниципаль җир контроле органы тарафыннан юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның җир участогын тикшерү
АКТЫ
№ _______

Акт төзелде: ____________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(муниципаль җир контроле органының исеме)

«___»___________20___елда ______________________________________________ адресы буенча урнашкан __________________________ кадастр номерлы мәйданы _________________ кв.м булган, ___________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(юридик затның исеме, җитәкчесенең Ф.И.А.и., ИНН, юридик адресы, банк реквизитлары, телефоннары; шәхси эшмәкәрнең яки гражданның Ф.И.А.и., ИНН, паспорт мәгълүматлары, яшәү урынының адресы, телефоны)

файдаланыла торган (бирелә торган, элек бирелгән) җир участогын тикшерү
(кирәклесенең астына сызарга)

үткәрелде.

Җир участогын тикшерүне үткәргән зат(-лар):

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(тикшерү үткәргән вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы)

катнашучылар: ________________________________________________________.

(җир участогын тикшергәндә катнашкан затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тикшерү дәвамлылыгы: _____________________.

Тикшерүне үткәрү барышында һәм җир участогына хокук билгеләүче

документларда күрсәтелгән мәгълүматларны исәпкә алып, билгеләнде:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(территорияне, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны тасвирлау, коймалар, межа билгеләре һ.б. булу)

Тикшерү барышында башкарылды: ________________________________

Теркәлгән документлар: ______________________________________

Җир участогын тикшерүдә башка катнашучылар: _________ / ______________/
(имза) (Ф.И.А.и.)

Тикшерүне үткәргән вазыйфаи
затның (зазатларның) имзасы: _________ / _______________/
(имза) (Ф.И.А.и.)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен
гамәлгә ашыруның
административ регламентына
4 нче кушымта

____________________________________________________________

____________________________________________________________

(җирле үзидарә органының яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән

____________________________________________________________

____________________________________________________________

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органның исеме)

______________________ ______________________

(төзү урыны) (төзү датасы)

Ачыкланган Россия Федерациясе җир законнары
таләпләрен бозуны бетерү турында
КҮРСӘТМӘ

__________ дан __________ кадәр чорда ____________________

____________________________________________________________

(тикшерү үткәргән вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

Россия Федерациясе җир законнары таләпләренең үтәлешенә тикшерү үткәрелде ________________________________________

____________________________________________________________

(оешманың исеме, аның җитәкчесенең, шәхси эшмәкәрнең, гражданның Ф.И.А.и.)

нәтиҗәдә җир участогыннан тиешенчә файдаланмау билгеләнде:

____________________________________________________________

____________________________________________________________

(кимчелек җибәрелгән җир участогының (булганда) мәйданын, урнашу урынын, кадастр номерын күрсәтеп, кимчелекләрне тасвирлау, норматив хокукый актларның исемнәре, таләпләре бозылган шундый актларның структур берәмлекләренә сылтамалар һәм аның өчен билгеләнгән җаваплылык)

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 маддәсенә таянып,

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ

____________________________________________________________

(оешманың исеме, аның җитәкчесенең, шәхси эшмәкәрнең, гражданның Ф.И.А.и.)

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, «____» ____________20___елга кадәр күрсәтелгән кимчелекне бетерергә.

Россия Федерациясе җир законнары таләпләрен бозуны бетерү срогын озайту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен күрсәтмә бирелгән зат күрсәтмә чыгарган затка түбәндәгеләрне тапшырыга хокуклы:

- кимчелекне бетерү срогын озайту турында үтенеч;

- кимчелекне бетерү өчен тиешле чаралар күрүне раслаучы документлар, белешмәләр һәм башка материаллар.

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 маддәсе нигезендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның Россия Федерациясе законнарын бозуларны бетерү турындагы законлы күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләнде.

Күрсәтелгән кимчелекне билгеләнгән срокта бетермәгән очракта, Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрү өчен, күрсәтмәне үтәмәү турындагы мәгълүмат

________________________________________________________________

(дәүләт хакимияте органының яки җирле үзидарә органының исеме)

җибәрелә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 54 маддәсе нигезендә, дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы яки җирле үзидарә органы Россия Федерациясе Җир кодексының 71 маддәсенең 9 пунктында күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны алганнан соң, судка җир участогын тартып алу турында таләп җибәрә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 76 маддәсе нигезендә, җир участогына хокукы тукталу гаепле затны җиргә кагылышлы хокук бозу нәтиҗәсендә китергән зыянны каплаудан азат итми.

________________________________________________________________

(хокукларны башкача аңлату, өстәмә мәгълүмат (кирәк булганда), кимчелекләрне бетерү тәртибе һәм ысуллары турында рекомендацияләр)

________________________________________________________________

(күрсәтмә чыгарган вазыйфаи затның имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

________________________________________________________________

(күрсәтмәне алган затның имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яисә күрсәтмәне алган затның аны имзалаудан баш тартуы турында билге, яисә почта элемтәсе аша җибәрү турында билге)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен
гамәлгә ашыруның
административ регламентына
5 нче кушымта

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(җирле үзидарә органының яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органның исеме)

__________________________ (төзү урыны) __________________________ (төзү датасы)

## Россия Федерациясе җир законнарының мәҗбүри таләпләрен һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуны булдырмау турында КИСӘТҮ №

______________________________________________________________________

(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең, гражданның Ф.И.А.и.)

Россия Федерациясе Җир кодексының 25 маддәсенең 1 пунктында һәм 26 маддәсенең 1 пунктында билгеләнгән мәҗбүри таләпләр

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(норматив хокукый актлар, аларның күрсәтелгән таләпләрне күздә тотучы структур берәмлекләре)

Җир участогы (җир участогының өлеше), мәйданы _____________кв.м,
адресы: ____________________________________________________,
кадастр № __________________________________________________,
рөхсәт ителгән файдалану төре _________________________________,
файдаланучы (хокукка ия) _______________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(нәтиҗәсе булып мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәмәү торган эш итүләр (эш итмәләр), мәйданын, урнашу урынын, кадастр номерын күрсәтеп җир участогына (булганда) тасвирлама)

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 маддәсенә, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.2 маддәсенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 нчы карарына, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ санлы Законына таянып,

Т Ә К Ъ Д И М   И Т Ә М

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(юридик затның исеме, аның җитәкчесенең Ф.И.А.И., шәхси эшмәкәрнең, гражданның Ф.И.А.и.)

1. РФ Җир кодексының 25 маддәсенең 1 пункты һәм 26 маддәсенең 1 пункты нигезендә мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча чарарлар күрергә

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

2. 60 (алтмыш) көннән ким булмаган срокта Кисәтүне үтәү турында белдерү кәгазе җибәрергә. Белдерү кәгазендә мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматлар күрсәтелә.

3. 60 (алтмыш) көннән ким булмаган срокта бирелгән Кисәтүгә карата позицияне нигезләп каршылыклар җибәрергә.

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(муниципаль җир контроле органының элемтә мәгълүматлары, адресы, телефоны, электрон почта адресы)

_______________________________________________________________________

(кисәтү чыгарган вазыйфаи затның имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________________________

(кисәтүне алган затның имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яисә кисәтүне алган затның аны имзалаудан баш тартуы турында билге, яисә почта элемтәсе аша җибәрү турында билге)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен
гамәлгә ашыруның
административ регламентына
6 нчы кушымта

________________________________________________

________________________________________________

(җирле үзидарә органының яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән

________________________________________________

________________________________________________

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органның исеме)

________________________ ________________________

(төзү урыны) (төзү датасы)

## Муниципаль җир контроле буенча планлы тикшерүнең тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)

________________________________________________

(муниципаль контроль органының исеме)

________________________________________________ нигезендә

(муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең тикшерү үткәрү турында
боерыгының реквизитлары)

________________________________________________

(тикшерүләрнең бердәм реестрында тикшерүнең исәп номеры һәм тикшерүгә исәп номеры бирү датасы)

________________________________________________

(планлы тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

________________________________________________

(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

________________________________________________

юридик затның/шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек төре, производство объекты, тибы, характеристикасы,
куркынычлык категориясе, куркынычлык классы)

________________________________________________

(тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны һәм (яки) юридик зат, шәхси эшмәкәр
тарафыннан файдаланылучы производство объектларна күрсәтмә)

________________________________________________

(муниципаль контроль төрен оештыру һәм үткәрү тәртибендә каралган очракта, планлы тикшерү предметын
тикшерү кәгазе формасында бәян ителгән мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар нигезендә
билгеләнгән таләпләр белән чикләүгә күрсәтмә)

| Т/с | Сораулар * | Мәҗбүри таләпләр билгеләнгән норматив хокукый актларның реквизитлары | Җавап вариантлары | |
|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк |
| 1 | Җир участогына оештыру документлары булу | РФ Җир кодексының 25, 26 маддәләре, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенең 3 пункты | | |
| 2 | Хокук билгеләүче документлар нигезендә җир участогыннан файдалану (рөхсәт ителгән файдалану) | РФ Җир кодексының 42 маддәсе | | |
| 3 | Законнар нигезендә җир участокларында урнаштырылган межа, геодезия һәм башка махсус билгеләрне саклау | РФ Җир кодексының 42 маддәсе | | |
| 4 | Җирләрне саклау буенча чараларны, шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру | РФ Җир кодексының 42 маддәсе | | |
| 5 | Җир өчен түләүләрне үз вакытында гамәлгә ашыру | РФ Җир кодексының 42 маддәсе | | |
| 6 | Җир участокларын үз вакытында үзләштерү | РФ Җир кодексының 42 маддәсе | | |
| 7 | Җир участогыннан файдалану хокукын алу тәртибен үтәү | РФ Җир кодексының 22 маддәсенең 2 пункты | | |
| 8 | Җир законнарын бозуны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәү | РФ Җир кодексының 71 маддәсенең 7 пункты | | |

* Җирле үзидарә органы компетенциясе чикләрендә исемлеккә өстәмә сораулар өстәлергә мөмкин

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(исемлектәге сораулар буенча аңлатмалар һәм өстәмәләр)

Тикшерү үткәрүче затның имзасы:

________________________________ ________________________________

(фамилия, инициаллар)

Юридик зат җитәкчесенең
(шәхси эшмәкәрнең), гражданның имзасы:

________________________________ __________________________________________

юридик зат, шәхси эшмәкәрнең, гражданның фамилиясе,
исеме, атасының исеме (булганда)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен
гамәлгә ашыруның
административ регламентына
7 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
муниципаль җир контролен үтәүнең административ процедураларының (гамәлләренең)
блок-схемасы

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан җирләрдән файдалану мәсьәләләрен җайга салучы Россия Федерациясе, Татарстан Респубикасы законнарының һәм башка норматив актларның үтәлешен тикшерә башлау, тикшерүне үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү

↓

Муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең тикшерү үткәрү турында боерыгы (приказы)

↓

Юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга тикшерү үткәрү турында хәбәр итү

↓

Тикшерүне үткәрү

↓


Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле, җирләр торышы һәм алардан файдалану турында мәгълүматларны һәм материалларны, шул исәптән җир участокларына һәм аларда урнашкан объектларга хокукларны раслаучы документларны, җир участокларыннан файдаланучы затлар турында мәгълүматларны алу

↓

Тикшерүне үткәрү срогын озайту

← Юк ↓

→ Әйе → Муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең тикшерүне үткәрү срогын озайту турында боерыгы (приказы) ↓


Тикшерүне тәмамлау өчен кирәкле өстәмә чаралар үткәрү
Тикшерүнең тәмамлануы
Тикшерү акты төзү
Күрсәтмә бирү